РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

12 декабрь, 2025 ел Кукмара ш. № 25

Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрен Киров өлкәсе чиге белән чиктәш урында Татарстан Республикасы чигенә туры китерү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы, «Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрен туры китерү турында» Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының 2025 елның 7 ноябрендәге 20 номерлы карары, Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Кукмара муниципаль районы халкының фикерен исәпкә алып, гавами тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре буенча Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде**:

1. Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрен Киров өлкәсе чиге белән чиктәш урында Татарстан Республикасы чигенә туры китерү белән килешергә.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр төзелеше һәм торак-коммуналь хуҗалык, табигый ресурслар һәм җирдән файдалану буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Район башлыгы С.Д. Димитриев